ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 11-26/тко

«Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-72/кс карары белән расланган озак сроклы чик тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 01.12.2017 № 10-72/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 № 10-103/кс карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
01.12.2017 № 10-72/кс карарына
1 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 11.12.2019
№ 11-26/тко карары редакциясендә)

## Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Әтнә муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 314,72 | 314,72 | 320,05 | 330,22 | 305,74 | 305,74 |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 266,71 | 266,71 | 266,71 | 275,18 | 254,78 | 254,78 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-72/кс карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 11-26/тко карары редакциясендә)

Каты коммуналь калдыкларны күмүгә «Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Атнинское ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2018 | 1201,91 | 1 | - | 1,97 |
| | | 2019 | 1244,62 | 1 | - | 1,97 |
| | | 2020 | 11432,48 | 1 | - | 1,97 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге